31.08.2018елда үткән педагогик
киңәшмәдә каралды
Беркетмә: 1

3 нче " Чишмәкәй" мәктәпкәчә
белем муниципаль бюджет
учреждениесе мөдире раслады
һәм 03.09.2018елның 74/О
боерыгы нигезендә гамәлгә
кертелде
_________ А.И.Ахметвалиева

# Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авылының 3 нче "Чишмәкәй" мәктәпкәчә белем муниципаль бюджет учреждениесенең

# 2018-2019 нче уку елына еллык эш планы

**Эчтәлек**

**I- бүлек**
1.1.Бакча турында мәгълүмат..........................................................................................3
1.2.Бакчаның узган уку елына балаларга тәрбия-белем бирү эшенә анализ................5
1.3.Тема,максат һәм бурычлар 2018-2019 нче уку елына гомуми мәгълүмат..............17
1.4.Балалар бакчасында кулланыла торган программалар...........................................17
**II - бүлек. "Мәгариф турында" законнарның үтәлеше**
2.1."Мәгариф турында" законнарның үтәлеше буенча эш планы...............................18
**III - бүлек. Кадрлар белән эшне оештыру**
3.1.Кадрлар турында белешмә..........................................................................................20
3.2.Социаль активлыкны, үз белемеңне күтәрү. Эш квалификациясен үстерү............20
3.3.Педагогларны аттестацияләү,белем күтәрү курслары...........................................21
3.4.Аттестациягә баручы педагог белән эш планы.......................................................22
3.5.Педагогларны аттестацияләү.....................................................................................22
3.6.Тәрбиячеләрнең үз белемен күтәрү темалары..........................................................22
3.7.Тәрбиячеләр өчен консультацияләр...........................................................................23
3.8.Педагогик киңәшмәләр................................................................................................24
3.9.Семнарлар....................................................................................................................27
3.10.Ачык эшчәнлекләр.....................................................................................................28
**IV - бүлек. Тәрбия-белем бирү эшен яхшыртуга эшчәнлеге**
4.1. Методик киңәшмәләр.................................................................................................29
4.2.Бакча мөдире белән бергә үткәреләчәк методик сәгатьләр.....................................30
4.3. Бәйрәмнәр, күңел ачу чаралары,экскурсияләр.........................................................31
4.4..Күргәзмәләр, конкурслар............................................................................................33
4.5.Методик бүлмәне баету өстендә эш..........................................................................34
4.6. Гомуми хезмәт коллективы җыелышлары...............................................................36
4.7.Инструктажлар, укыту.................................................................................................36
4.8. Мөдир каршындагы административ утырышлар....................................................37
4.9. Тәрбия һәм белем бирү эшенә педагогик контроль..................................................38
4.10.ПМПк (консилиум) эшен оештыру...........................................................................39
4.11.Әти-әниләр белән эш...................................................................................................40
4.12. Балалар бакчасының мәктәп белән дәвамчанлык эш планы..................................43
**V - бүлек. Административ-хуҗалык эшләре**
5.1. Административ-хуҗалык эшләре...............................................................................45
**VI - бүлек. 2018– 2019 уку елының җәйге сәламәтләндерү чорына эш планы**.......47
**VII - бүлек. Тәрбия-белем бирү планына кушымталар**
7.1. План проведения мероприятий по пожарной безопасности.................................55
7.2 Юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтү буенча 2018-2019 нчы уку елына эш планы............57
7.3. План мероприятия по обеспечению антитеррористической защищенности..........59
7.4. Работа по профилактике травматизма......................................................................63
7.5.План мероприятий по противодействию коррупции в МБДОУ..............................64
7.6. База балалар бакчасының эш планы..........................................................................66
7.7. " Гаилә торышы" проекты буенча төркемнәрдә тематик көннәр планы..............70

## I- бүлек.   1.1. Бакча турында мәгълүмат

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авылының 3 нче “Чишмәкәй” муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе

**Адресы:** Чирмешән районы, Чирмешән авылы, М.Титова урамы № 24  нче йортка урнашкан.

**Төре:** гомумиүстерешле

**Эш сәгате:** 7.30-18.00.

**Эш режимы** – 10,5 сәгать.

**Ял көннәре:** шимбә ,якшәмбе,гомуми халык бәйрәм көннәре.

**Барлыгы**: 4 төркем.
**Телефон номеры-** 8(84396) 2-52-70,
**Электрон почтасы**: Alsinya.Ahmetvalieva@tatar.ru
**Бакчаның сайты** : https://edu.tatar.ru/cheremshan/dou3

**Бакчаның мөдире- Ахметвалиева Алсинә Ильяс  кызы:**
-югары белеме;
- педагогик стажы-39 ел, бу вазыйфада-29 ел

**Шәфкатъ туташы- Хуснуллина Зөлфирә Мансур кызы:**
- махсус урта белемле;
- югары квалификацион  категориягә ия;
- эш стажы-27ел

**Хезмәткәрләр һәм белгечләр турында мәгълумат**

Балалар бакчасында 25 хезмәткәр эшли. Шуларның 10-ы педагоглар. Барлык педагогларда татар һәм рус телләрендә иркен аралашалар.

***Белемнәре буенча:***




*Категорияләре буенча:*




***Белгечләр:***

1. Музыка җитәкчесе - 1;
2. Рус теле тәрбиячесе -1 ;
3. Физик тәрбия җитәкчесе - 1;
4. Укытучы-логопед - 1.

| **"Чишмәкәй" балалар бакчасында тәрбияләнүче балаларның милли составы** | | | |
|---|---|---|---|
| **Еллар** / **Баланың милләте** | 2016-2017 | 2017-2018 | 2018-2019 |
| татар | 57 | 43 | 44 |
| рус | 15 | 21 | 18 |
| Башка милләт | 13 | 10 | 11 |
| **Бала саны** | 85 | 74 | 73 |

**Балаларның социаль паспорты**

| Категория | 2016-2017 нче уку елы | 2017-2018 нче уку елы | 2018-2019 нче уку елы |
|---|---|---|---|
| Барлыгы | 85 | 74 | 73 |
| опекадагы балалар | 0 | 0 | 0 |
| инвалид балалар | 0 | 0 | 0 |
| күп балалы гаиләләр | 10 | 13 | 21 |
| малайлар | 48 | 41 | 40 |
| кызлар | 37 | 33 | 33 |

## 1.2.“Чишмәкәй” балалар бакчаның 2017-2018 уку елына балаларга тәрбия-белем бирү эшенә анализ

2017 -2018 нче уку елында 4 төркемдә барлыгы 74 бала тәрбияләнде һәм белем алды. Ел дәвамында 10 педагог хезмәт куйды. “Чишмәкәй” балалар бакчасы 2017-2018 уку елында “Социаль мөхиткә яраклашкан,сәламәт ,культуралы,яшь үзенчәлекләренә туры килгән белем-күнекмәләр үзләштергән ,белем алганда УМК нигезләнеп ФДББСн кабул итә алырлык шәхес тәрбияләү” дигән **тема** астында эшләде.

Бакчада балаларның уен сәләтен, интеллектуаль һәм шәхси үсешен тәэмин итү, иҗат мөмкинлекләрен ачу һәм үстерүгә нык игьтибар ителә. Тәрбиячеләребез балаларга белем-тәрбия бирүдә заман таләпләренә туры килә торган “Туганнан алып мәктәпкә кадәр” (Н.Е.Веракса) программасына нигезләнеп төзелгән балалар бакчасының “Белем бирү программасы” буенча эшли.Бу программа үз алдына балаларны бар яклап та сәламәт шәхес итеп үстерү, аңа мәктәптә уку–тәрбия алу өчен кирәкле психологик процесслар булдыруны **максат** итеп куя.

Укыту – тәрбия процессын камилләштерү һәм аның нәтиҗәлеген күтәрү өчен педагоглар алдына түбәндәге **бурычлар** куелган иде:

1. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга кече яшьтән юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтү, тормыш иминлекләрен саклау
2. Балаларны ике Дәүләт телленә сыйфатлы өйрәтүне тәимин итәргә.
3. Әти-әниләрне балаларга ике дәүләт телен өйрәтү буенча яңа укыту-методик комплектлар белән таныштыруны дәвам итү, балаларга белем һәм тәрбия бирү эшчәнлегендә балалар бакчасы һәм гаиләнең хезмәттәшлеген арттырырга.

Әлеге максатны тормышка ашыру өчен педагоглар һәрчак эзләнделәр, яңа алымнар өйрәнергә омтылдылар. Коллектив балаларның сәламәтлеген саклауга , балаларда әдәплелек, әхлакый сыйфатлар тәрбияләүгә һәм шәхси үсешләрен тәэмин итүгә зур игътибар бирде. Тәрбия - белем бирүдә программаның барлык юнәлешләрен (социаль-коммуникатив, сөйләм үстерү, танып белү, нәфис-нәфасәти үсеш, физик үсеш) гамәлгә ашыру өчен көч куелды.

***ФДББС нигезендә балалар бакчасының төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыру буенча эш нәтиҗәләре***

Балаларның белем дәрәҗәләрен, программа үтәлешен ачыклау максатыннан ел дәвамында балалар белән 2 тапкыр педагогик диагностикалар уздырылды. Нәтиҗәләре буенча мониторинг төзелде

***Балаларның мәктәпкә әзерлек дәрәҗәсе***. Тикшерү көннәрендә тәрбиячеләрнең тәрбия-белем бирү буенча алып барыла торган эше өйрәнелеп, балаларның мәктәпкә әзерлек дәрәҗәсе буенча эшкә анализ ясалды. Тәрбиячеләр һәм балалар белән әңгәмәләр үткәрелде. Балаларның мәктәпкә мөнәсәбәте, аларның мәктәпкә әзерлек дәрәҗәсен ачыклау максатыннан, сөйләмнең, балаларның язуга кулларының әзерлеген билгеләү буенча тестлар, диагностика үткәрелде.

***Мәктәпкә әзерлек буенча диагностика күрсәткечләре:***

Әзерлек төркеменә йөрүче 14 баланың **мәктәпкә әзерлек дәрәҗәсе тикшерелде.** Тикшерү традицион методика нигезендә, подгруппа методы белән алып барылды.

| | **Ел башы** | **Ел азагы** |
|---|---|---|
| | бала | бала |
| **IV дәрәҗә** (средний балл от 3,2 до 4,0) - высокие показатели состояния ВПФ и процессов | 2 | 4 |
| **III дәрәҗә** (средний балл от 2,60 до 3,19) - средний уровень развития | 6 | 10 |
| **II дәрәҗә** (средний балл от 2,0 до 2,59) – показатели ниже средних | 5 | - |
| **I дәрәҗә** (менее 2 баллов) – низкие показатели | 1 | - |

**Нәтиҗә:** уку елында тәрбиячеләр НазыроваГ.Ш., Фартдинова Г.ш., Шарапова Э.М. балаларны мәктәпкә әзерләүгә җитди игътибар бирделәр. Балалар уку эшчәнлеге күнегүләрен яхшы үзләштерделәр; аларның танып белү эшчәнлеге үсеше бай; тирә-як турындагы белемнәре бай; математик әзерлекләре нормага туры килә.

Балалар бакчасында зурлар төркеменнән башлап балаларга рус теле өйрәтелә.

**Балалар белән үткәрелгән диагностика нәтиҗәләре:**

| **Балаларның биремнәрне үтәү дәрәҗәсе( рус теле)** | **Зурлар төркеме** | **Мәктәпкә әзерлек төркеме** |
|---|---|---|
| Югары | 43% | 67 % |
| Уртача (яхшы) | 57 % | 33% |
| Уртачадан түбән | 0 % | 0 % |

**Нәтиҗә:** Тәрбияче Шарапова Э.М. арафыннан тел өйрәтүдә инновацион алымнардан оста файдалану, эшне максатчан һәм даими алып бару нәтиҗәсендә балларның рус теле белү дәрәҗәсе югары.

**Балаларның белем күрсәткечләре мониторинг буенча**




**Нәтиҗә:**

***«Физик үсеш»*** белем бирү өлкәсе буенча программа материалларын барлык төркемнәр дә югары һәм уртача дәрәҗәдә үзләштерде. Алга таба да эшне дәвам итеп, төп хәрәкәт төрләрен ныгытуга һәм физик сыйфатлар үсешенә игътибар итәргә кирәк.

***«Танып-белү»*** белем бирү өлкәсе буенча да балалар программа таләпләрен югары һәм уртача дәрәҗәдә үзләштерүләрен күрсәттеләр. Әйләнә –тирә белән таныштыру, иң гади математик күзаллаулар булдыру буенча эшне төрлеләндерүгә, балаларның кызыксынуларын үстерү өстендә эшне яхшыртырга.

**«Сөйләм теле үстерү» белем бирү өлкәсе** буенча программа материалын барлык балалар да яхшы үзләштерде. Балаларны матур әдәбият әсәрләрен игътибар белән тыңларга өйрәтүне, шигырьләрне сәнгатьле итеп сөйләүгә ирешүне максат итеп куярга, шулай ук әдәби әсәрләр жанрлары турында балаларның белемнәрен үстерергә киңәш ителде.

**«Сәнгати-эстетик- үсеш » белем бирү өлкәсе** буенча шулай ук уртача һәм югары күрсәткечләргә ирештек. Барлык төркем балалары да программа материалларын яхшы үзләштерде.

Ата-аналар белән балаларның сәламәтлеген ныгыту буенча системалы эш оештырылды: чыгышлар ясалды, "Әти, әни, мин — сәламәт гаилә", "Сәламәт булыйк", "Ел үсәсен, көн үсәбез" һ.б.китап—ширма, папка передвижка тутырылды.

**Балаларның авыру буенча калдырган көннәре**

| Еллар | Бер балага ничә көн калдырылган |
|---|---|
| 2016 елның 1 январена | ***5,9 көн*** |
| 2017 елның 1 январена | ***3,7 көн*** |
| 2018 елның 1 январена | ***2,1 көн*** |

**Нәтиҗә:**

Авыру сәбәпле бер баланың калдырган көннәр саны 2018 елга караганда 1,6 кә кимеде.

**Тәкъдим:**

- түбән күрсәткечләр бирүче балалар белән эшләү өчен шәхси эш планы төзү.
- ата-аналарга бердәм тәрбия бирү өчен өйдә дә шартлар тудырырга кирәклеге турында тәкъдимнәр бирү.

**Кадрлар белән эшне оештыру**

**Педагогларның һөнәри осталыгын күтәрү буенча эш нәтиҗәләре**

2017-2018 нче уку елында балалар бакчасы педагогик кадрлар белән тулысынча тәэмин ителде,белем күтәрү курсларын барлык педагоглар да үтте.

**Педагогларның аттестация үтүе**

| | 2016-2017 уку елы | 2017-2018 уку елы |
|---|---|---|
| **Барысы** | **10 педагог** | **10 педагог** |
| **Югары кв. категория** | 2 | 2 |
| **1 кв.категория** | 4 | 5 |
| **категориясез** | 4 | 3 |
| **Категорияле педагоглар саны** | 6 | 7 |

2017-2018 нче уку елында Шарапова Э.М. ( рус теле тәрбиячесе) квалификацион категориясен раслады, Фартдинова Г.Р. беренче квалификацион категориягә үтте.

**Нәтиҗә:** Саннардан күренгәнчә, югары категорияле педагогларнын саны бер урында тора. Бу категория алу процессының катлаулануы белән бәйле. Алдагы елларда педагогларның категориясен күтәрү өстендә эшне дәвам итү бурыч булып тора.

Белем күтәрү курсларын барлык педагоглар да үтте.

**Педагогик кадрларның белем дәрәҗәсе**

| Уку елы | Педагоглар саны | белеме | |
|---|---|---|---|
| | | югары | Махсус урта |
| **2016-2017** | 10 | 6 | 4 |
| **2017-2018** | 10 | 7 | 3 |

**Анализ:** Саннардан күренгәнчә, педагогларның белемнәрен күтәрү өстендә эш алып барыла.

Тәрбия-белем бирү эшендә педагоглар яңа технологияләрдән, инновацион методик материаллардан киң файдаландылар. Һәр килгән журнал, газеталарны, чыккан методик әсбапларны даими өйрәнү педагогларга һөнәри осталыкларын үстерүгә булышлык итте. Вакытлы матбугат белән вакытында танышып бару тәрбиячеләргә өйрәнелгән заманча методларны, эш алымнарын үзләренең эшләрендә нәтиҗәле файдаланырга мөмкинлек бирде.

Тәрбиячеләр үзләренең белемен, сәләтен, белем бирү материалын үзләштерүне үстерү өчен педагогик эш тәҗрибәләрендә яңа педагогик технологияләр, уңышлы эш алымнарын кулланып эшләделәр.

Педагогларыбыз үз тәҗрибәләре белән районыбызның һәм зона куләмендә үткәрелгән төрле балалар бакчаларында уртаклашты, чыгышлар ясады, семинарларда тәрҗрибә уртаклаштылар.

Уку елы дәвамында педагоглар белән 4 педагогик киңәшмә, семинар-практикумнар,конкурслар,консультацияләр үткәрелде. Бу киңәшмәләрдә балаларның физик, психик, социаль үсешенә кагылышлы актуаль мәсәләләр һәм кече яштәге балаларның бакчага ияләшү соруалары, физик сәламәтләндерү эшләрен һәм халык традицияләренә,

милли гореф-гадәтләренә нигезләнеп, әхлакый хисләр тәрбияләүне оештырулар, ФДББС һәм УМК таләпләренә туры китереп тәрбия-белем бирү эшен яңартулар каралды.
Бакча мөдире Ахметвалиева А.И. 2017-2018нче уку елы планының эчтәлеген алып барды.

Яңа уку елы ***“2016-2017 нче уку елына йомгак,2017-2018 нче уку елының эш планын кабул итү”*** -темалы педагогик киңәшмәсе белән ачып җибәрдек. Балалар бакчасының мөдире Ахметвалиева А.И.уку елында башкарылган эшләргә, уздырылган чараларга тукталып үтте, коллектив алдында еллык планда каралган барлык эшләрне дә яңа алымнар, технологияләр, тәрбияви максатлы эшчәнлекләр, чаралар аша югары дәрәҗәдә башкарып чыкканнарын тәрбиячеләргә әйтеп китте.

Бакча мөдире Алсинә Ильяс кызы еллык эш планының эчтәлеге белән тәрбиячеләрне таныштырды, тәрбиячеләр еллык план проектын тикшерүдә катнашып, үзләренең фикерләрен әйтеп үттеләр. Еллык эш планын хезмәткәрләр гомуми җыелышында кабул иттек.

Төркемнәрнең торышы тикшерелде, хәзерлекләренә уңай бәя бирелде.

Бакчада балаларның физик, интеллектуаль һәм шәхси үсешен тәэмин итү, иҗат мөмкинлекләрен ачу һәм үстерүгә нык игьтибар ителде. Балаларга тәрбия-белем бирү эшендә бертөрлелектән арына барып, заман таләпләренә туры килә торган яңа программалар, яңа технологияләр кулланып, эш оештырылды.
Яңа укыту-методик комплектларын гамәлгә кертү нигезендә, тәрбия–белем бирү эшенең эчтәлеген баету, сыйфатын күтәрү максатыннан, эшне заман мәгариф технологияләренә һәм яңа методикаларга, УМК” Говорим по-татарски”, “Изучем русский язык”, “Туган телдә сөйләшәбез” гә нигезләнеп алып барылды. Балалар бакчасында икенче педагоглар киңәшмәсе
**«Осталыкның нигезе-тырышлык»** дип аталды. Шушы педагогик киңәшмә алдыннан “Балалар бакчасында рус/ана телен өйрәтүдә яңа педагогик технологияләр куллану” темасына бакча педагоглары белән семинар-практикум узды.

Киңәшмәдә рус теле тәрбиячесе Шарапова Э.М., логопед Муратшина Г.М.,тәрбияче Фартдинова Г.Р. чыгышлар ясадылар.Чыгышлар үз тәҗрибәләренә таянып язылган иде.
Өченче педагоглар киңәшмәсе **:” ФДББС нан чыгып бакча белән гаиләләр арасында хезмәттәшлекне оештыруга бүгенге көн таләпләре”** темасына багышланып, шул теманы яктырткан ачык чаралар күрсәтелде.
Дүртенче педагоглар киңәшмәсе ***“*Узган 2017-2018 нчы уку елына йомгак.**
**Җәйге сәламәтләндерү чорына эш планы кабул итү*”*** темасы астында үтте. Педсоветлар план нигезендә тиешле дәрәҗәдә үткәрелде.

Тәрбия һәм белем бирү эшенең системалы баруын,балаларга сыйфатлы белем бирүне күзәтү максатыннан тәрбиячеләр һәр кварталны йомгаклау буенча белем бирү эшчәнлекләрен күрсәттеләр. Самарханова В.Г., Сибгатуллина А.Р., Гилязова Г.М. үткәргән белем бирү эшчәнлекләре ФДББСна нигезләнеп дөрес методик таләпләргә туры килеп, югары дәрәҗәдә үтте. Тәрбиячеләр үзләренең белемен, сәләтен, белем бирү материалын үзләштерүне үстерү өчен педагогик эш тәҗрибәләрендә яңа педагогик технологияләр, уңышлы эш алымнарын кулланып эшләделәр.

Ел дәвамында план нигезендә чаралар,күргәзмәләр һәм конкурслар үткәрелде,аларга нәтиҗәләр ясалды. Уку елы агышында үткәрелгән һәр чарага тәрбиячеләр тәрбияви максатны алга куеп, иҗади якын килделәр. Нәтиҗәдә бу чараларны уздыру барышында тәрбиячеләр үзләренең яхшы оештыру сәләтләрен күрсәттеләр һәм аларның иҗади эшчәнлеккә омтылышлары артты.

**Всероссийский:**

1)Всероссийский открытый конкурс творчества “Тукай безнең күңелләрдә”- “ Тукай в наших сердцах”, диплом 2 степени награждается Адельшина Ралина. В номинации “Художественное творчество”

2)Всероссийский открытый конкурс творчества “Тукай безнең күңелләрдә”- “ Тукай в наших сердцах”, диплом 3 степени награждается Зиганшина Дания. В номинации “Декаративно-прикладное творчество”

3)Всероссийский конкурс творчества Лэпбук по речевому развитию с помощью мелкой моторики рук” Говорящие пальчики”, диплом 2 степени награждается воспитатель Шарапова Э.М.

4) Всероссийский конкурс «Здоровьесбережение в ДОУ», диплом победителя 1 место награждается учитель-логопед Муратшина Г.М

5) Всероссийский конкурс «Праздник правильной речи (для учителей-логопедов)» диплом победителя 1 место награждается учитель-логопед Муратшина Г.М

6)Всероссийский конкурс Инновационные технологии в ДОО (ТРИЗ в речевом развитии детей дошкольного возраста»)»диплом победителя 2 место награждается учитель-логопед Муратшина Г.М

**Республиканский:**

1) “СӘЙЯР” балалар һәм яшүсмерләр республика театр фестивалендә “Сәхнә балкышы” номинациясендә “Чишмәкәй” балалар бакчасы театр коллективы диплом белән бүләкләнде.
2) Грамотой за 1 место в муниципальном этапе республиканского конкурса “Зеленый огонёк-2018” награждается Сибгатуллина А.Р.

**Муниципальный:**

1) Конкурс«Родные истоки», грамота победителя в номинации «История моей малой Родины» награждается Самарханова В.Г.

2)Смотр-конкурс на лучшую разработку авторского дидактического пособия в технике «Лэпбук»-призёр Мусина З.З. В номинации «Лэпбук по познавательному развитию»

3)Смотр-конкурс на лучшую разработку авторского дидактического пособия в технике «Лэпбук»-победитель Сибгатуллина А.Р. В номинации «Лэпбук по социально-коммуникативному развитию»

4)Смотр-конкурс на лучшую разработку авторского дидактического пособия в технике «Лэпбук»-призер Шарапова Э.М. В номинации «Изучаем русский язык»:

5)Конкурс профессионального мастерства воспитателей «Как я обучаю детей русскому языку?»

6) Конкурс творческих работ «Дорога БЕЗ опасности»- 2 место, Тузилов Павел в номинации «Маршрутный лист или чек-лист»

7)Конкурс творческих работ «Дорога БЕЗ опасности»- 1 место, Газимова Залина в номинации **«**Конкурс слоганов, стихов, частушек**»**

8) Конкурс детского наглядно-агитационного материала по пожарной безопасности-3 место, Зиганшина Дания, в номинации «Не допусти лесного пожара

9) Конкурс детского наглядно-агитационного материала по пожарной безопасности-1 место, Халиуллин Аслан, в номинации «Безопасный новый год»

10)смотр-конкурс на лучшую постановку народной сказки, победитель Шарапова Э.М. в номинации «Лучшая идея спектакля»

11) Конкурс детского рисунка « Конституция глазами детей»- 3 место, Каримов Рустам

**Нәтиҗә:** тәрбиячеләр үзләренең белемен, сәләтен, белем бирү материалын үзләштерүне үстерү өчен педагогик эш тәҗрибәләрендә яңа педагогик технологияләр, уңышлы эш алымнарын кулланып эшләделәр нәтиҗәдә балалар бакчасы коллективы:

- муниципаль конкурс” «Лучший билингвальный детский сад» -2 урын;
- муниципаль конкурс”Яңа уку елына әзерлек”2018-2019уку елына - I урын;

**Тәкъдим:** республика күләм бәйгеләргә актив катнашырга, педагогларга “Ел тәрбиячесе” конкурсында урын яуларга.

**«Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында Татарстан Республикасы Законын» тормышка ашыру** максатыннан, ана телен һәм рус телен өйрәтү, сөйләм үстерү, әдәби телдә сөйләшү күнекмәләре булдыру барлык төркемнәрдә дә «Туган телдә сөйләшәбез» һәм «Изучаем русский язык» укыту-методик комплектын кулланып, Идел буе халыкларының мәдәниятын һәм сәнгатен өйрәнү, рухи – әхлакый һәм патриотик тәрбия бирү, балаларда гражданлык хисе тәрбияләү эше тематик план нигезендә алып барылды. Балалар бакчасында төрле мәдәни чаралар: «Сөмбелә», «Карга боткасы», «Нәүрүз», «Сабантуй» үткәрелде.

Бакчада балаларны рус һәм ана теленә өйрәтү, сөйләм телен үстерү өчен барлык шартлар да тудырылган. Төркемнәрдә һәм рус теленә өйрәтү бүлмәсендә яшь үзенчәлекләре буенча төрле методик әсбаплар, дидактик уеннар, кулланылган программа һәм УМК буенча төрле күргәзмә һәм тарату әсбаплары, татар телендә мультфильмнар, аудиоязмалар бар.

Балалар бакчасында педагоглар өчен семинарлар үткәрелде:

- «Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның танып белү үсеше»,
- «ФДББСн тормышка ашыру шартларында, мәктәпкәчә яшьтәге балаларны өйрәтүдә танып-белү эшчәнлеге үсешенә туры килерлек предметлы-үстерешле мөхит булдыру»,
- «ТР мәктәпкәчә яшьтәгеләргә милли белем бирү системасы үсеше».

**Тәкъдим:**ирешкән уңышлар белән генә тукталмаска,алга таба бу юнәлеш буенча нәтиҗәле эш алып барырга.

### Административ-хуҗалык эшләренә анализ

Балаларның балалар бакчасында йөрү материаль-техник шартлары белем һәм тәрбия бирү методларына һәм эчтәлегенә туры килә. Балалар бакчасы дәүләт нормаларына һәм таләпләренә туры китереп җиһазландырылган.

Балаларга саф һавада йөрү өчен территория җитәрлек, көн дәвамында урамда уйнау, күзәтү шартлары булдырылган. Саф һавада мәйданчыклар урам белән чикләнгән, җитәрлек

дәрәҗәдә яшелләндерелгән. Әйләнә-тирә мөхит-тәрбия һәм баланың һәрьяклап үсеше өчен мөһим фактор. Җиһазлары куркынычсыз, сәламәтлек саклаучы, эстетик җәлеп итүче һәм белем дәрәҗәсен үстерүче. Җиһазлар балаларның яшенә һәм буена туры килә, уенчыклар эстетик һәм педагогик таләпларга туры килә, мәктәпкәчә-яшьтәге балаларга белем дәрәҗәсе үсүдә җитәрлек ярдәм итә.

Балаларның психофизик сәламәтлеген саклау һәм танып-белү эшчәнлеге үсешенә туры килерлек предметлы-үстерешле мөхит булдырылган. Дидактик уеннарның төрлелеге эшчәнлекләрдән тыш вакытта балаларның белемнәрен ныгытуга ярдәм итә.

Төркемнәрнең барлык урыннары да балаларга үтемле. Табигать почмагында балалар гөлләргә су сибү, өлкәннәр ярдәмендә аларны күчереп утырту кебек эшләр эшлиләр. Һава торышы билгеләү календарьләре балаларга табигать үзгәрешләрен күзәтергә ярдәм итә. Сәнгать иҗат, әдәбият, музыка, театр элементлары һәрбер төркемне бизәүдә кулланыла. Чишенү бүлмәләрендә иҗат күргәзмәләре урнашкан. Яшь үзенчәлекләрен исәпкә алу принцибы буенча, малайлар һәм кызларның аерым бәдрәфләре булдырылган.Бакчабызда барлык педагоглар да предметлы-үстерешле мөхит байлыгына зур әһәмият бирә. Шуның өстендә күп эшлиләр.

**Тәрбия һәм белем бирү эшенә җитәкчелек һәм контроль**

Эчке контроль алдан төзелгән план нигезендә алып барылды. Уку елы барышында тәрбиячеләр белән инструктажлар үткәрелде, тәрбиячеләрнең еллык эш планнары, документларны тиешенчә тутырулары, тәрбиячеләрнең эшчәнлекләр үткәрүе, ачык чаралары контрольда тотылды. Уку елы дәвамында тәрбиячеләрнең көндәлек планнары, документацияләре, уку – күрсәтмә әсбаплары тикшерелде, җитешсезлекләр мөдир яны киңәшмәләрендә анализланып, үз вакытында төзәтелде.

Тәрбия – белем бирү процессында анализ төрле формаларда үткәрелде:

- административ, оператив контроль эшләр, тематик, фронталь тикшерү;
- район балалар иҗаты фестивальләрендә, конкурсларында катнашу;
- педагогик диагностика (елына 2 тапкыр);
- балаларның кул эшләре күргәзмәләре; рәсемнәр күргәзмәләре.

*1 тематик тикшерү* – **“Тел өйрәнүдә, режим моментларында УМК куллануның нәтиҗәлелеген, төркемнәрдәге үстерелешле әйләнә – тирә мөхитне ачыклау”.** Әлеге тикшерү һәр төркемдә балаларны рус/ана теленә өйрәтү дәрәҗәсе; әлеге юнәлештә әти-әниләр арасында эшне пропагандалау исәбеннән тудырылган шартларны өйрәнү, бу шартларның Программа таләпләренә туры килүен ачыклау, анализ ясау; балаларда рус телен өйрәтү буенча педагогларның эш тәҗрибәсен өйрәнү максатыннан уздырылды. Балалар бакчасында балаларга тел өйрәнү өчен шартлар тудырылган, тәрбиячеләр тәрбия һәм белем бирү планнарында чагылдыралар. Барлык тәрбиячеләр дә, музыка җитәкчесе, рус теле тәрбиячесе белән тыгыз элемтәдә эшлиләр. Рус теле тәрбиячесе тарафыннан тәрбиячеләргә тиешле ярдәм күрсәтелә, киңәшләр, тәкъдимнәр бирелә.

*2 тематик тикшерү* –**"Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә физик үсешнең яңа формаларын кертү, сәламәт яшәү рәвеше күнекмәләрен формалаштыру буенча эшләрне оештыру”**дип аталды. Иң беренче тәрбиячеләрнең көндәлек режимны төгәл үтәп,

тәрбия - белем бирү эшен дөрес оештырулуы тикшерелде. Иртәнге гимнастика, физкультура эшчәнлекләре программага нигезләнеп, тиешле дәрәҗәдә алып барылуы каралды.

**“Мәктәпкә әзерлек төркемендә тәрбия һәм белем бирү процесының оештырылуы”** темасы астында фронталь тикшерү узды. Тикшерү көннәрендә тәрбиячеләрнең тәрбия-белем бирү эшчәнлеге өйрәнелеп, программаның бөтен бүлекләре буенча эшкә тирән анализ ясалды. Көндәлек планнары тикшерелеп, иҗат лабороторияләре каралды, режим моментлары күзәтелде. Педагоглар алга куелган максат-бурычларны, таләпләрне башкарып чыгалар; балалар программа материалын яхшы үзләштерәләр, ике дәүләт телендә дә җиңел аралашалар.Тикшерү дәвамында мәктәпкә әзерлек төркемендә уеннар,эшчәнлекләр,режим вакытлары каралды,анализ ясалды,тәкъдимнәр бирелде.Тикшерү нәтиҗәсе педагогик киңәшмә №4 таныштырылды.

Ел дәвамында тәрбиячеләрнең мөдир тарафыннан график буенча белем бирү эшчәнлекләре каралды һәр эшчәнлеккә анализ ясалды,киңәш,тәкъдимнәр бирелде.

Эчке контроль алдан төзелгән план нигезендә алып барылды. Уку елы барышында тәрбиячеләр белән инструктажлар үткәрелде; документларының тиешенчә алып барылуы; төркемнәрдә белем бирү эшчәнлекләренең үткәрелүе, ачык чаралар контрольда тотылды. Уку елы дәвамында тәрбиячеләрнең көндәлек планнары, документацияләре, күрсәтмә-таратма әсбаплар тикшерелде; җитешсезлекләр мөдир яны киңәшмәләрендә анализланып, вакытында төзәтелде. Ел дәвамында тәрбиячеләрнең мөдир тарафыннан график буенча белем бирү эшчәнлекләре каралды һәр эшчәнлеккә анализ ясалды,киңәш,тәкъдимнәр бирелде.

**Тәкъдим:** педагогларга балалар эшчәнлеген, белем бирү һәм режим вакытларында бара торган белем бирү эшчәнлекләрен, гомумән, ФДББС үзләштерүгә нигезләнеп, балаларның бакчадагы көн буена тиешле булган бала эшчәнлегенең төрле төрләрен ныклап планлаштырдыларга һәм оештырырга.

## Әти-әниләр белән эш системасы нәтиҗәләре

Бакчада **эти-әниләр белән эш** елдан-ел җанлана, төрләнә бара. Төркемнәрдә тәрбия темаларына консультацияләр, әңгәмәләр, ачык ишек көннәре, гаилә бәйрәмнәре, спорт бәйрәмнәре уздырыла. Әти-әниләр балалар бакчасы эше белән ныграк кызыксына, тәрбия-белем бирү эшенә күбрәк тартыла башладылар.Тәрбиячеләрнең эти-әниләр белән үткәргән эш формалары оригинальлеге, бай эчтәлеге белән аерылып тора, алар эти-әниләр белән һәр очрашуга ФДББС исәпкә алып, (җыелышлар, бәйрәмнәр һ.б.) җентекләп, җитди әзерләнәләр. Әти-әниләр үзләре дә чараларга теләп катнашалар.

Әти –әниләрне балалар бакчасында ике дәүләт телендә тәрбия һәм белем бирү системасы белән, милли тәрбия эшчәнлеге белән якыннан таныштыру максатыннан, түбәндәге җыелышлар уздырылды:

- «Баланың сөйләм үсешендә бармак уеннарының әһәмияте.»
- «Гаиләдә балага әхлак тәрбиясе бирүдә уеннар һәм аларның әһәмияте.»

Әлеге җыелышларда тел өйрәнүдә УМК куллану мәсьәләләре күтәрелде. Укытучы-логопед, музыка һәм физик тәрбия җитәкчеләре үзләренең балалар белән эшләүдә УМК кулланулары турында сөйләделәр.

Шулай ук ел дәвамында эти-әниләр белән әңгәмәләр, шәхси консультацияләр, бәйрәм чаралары, күргәзмәләр, конкурслар уздырылды.

**Нәтиҗә:** Ата-аналар белән 2017-2018 нче уку елына планаштырылган барлык чаралар да үтәлде.

**Балалар бакчасында балалар саләмәтлеген саклау өчен тудырылган шартлар**

Балалар бакчасында физкультура-сәламәтләндерү эшенең төп бурычы- балага тискәре әйләнә-тирә мөхитенә каршы тору сәләтен үстерү балаларның физик сәләтләрен ныгыту, төркемнәрдә чиктән тыш аруны бетерү ниятеннән уңай шартлар тудыру.

Балалар бакчасында мәктәпкәчә яшьтәге балаларның сәламәтләндерү һәм яшәү шартлары тудырылган. Спорт-сәламәтләндерү чаралары үткәрү өчен спорт залы, профилактик дәвалау чаралары үткәрү өчен медицина кабинеты эшли. Шулай ук төркемнәрдә балаларның мөстәкыйль физик эшчәнлеген оештыру өчен махсус җиһазландырылган почмаклар булдырылган. Балалар бакчасында комплекслы чыныктыру чаралары үткәрелә:

Балаларының сәламәтлеген саклау, ныгыту хәзерге көндә ата-аналарны, педагогларны иң борчыган мәсәләләрнең берсе. Шуннан чыгып үз алдыбызга түбәндәге мәсьәләләрне куйдык:

- хәрәкәт - бала өчен иң кирәкле шарт булуын күз уңында тотып, бакчада хәрәкәтле уеннарны үз югарылыгында уздыру;
- туклану - бала организмы өчен иң мөһиме шарт, шуңа күрә менюны сәламәтлекне саклау технологиясенә нигезләнеп төзү;
- организмны чыныктыру нәтиҗәсендә баланың салкынга, эссегә, авыруларга каршы торучанлыгын арттыру, чыныктыруны һәр балалның үзенчәлекләрен искә алып оештыру;
- балаларның бакчадан тыш вакытын дөрес оештыру буенча ата-аналар белән әңгәмәләр үткәрү;
- мәктәпкәчә яшьтәге балачак - сабыйның психик үсешендәге беренче чор, чөнки бу яшьтә шәхеснең бөтен психик сыйфатларына һәм үзенчәлекләренә нигез салына. Шуларны истә тотып, баланың һәрьяклакп үсеше өчен гаиләнең тәрбияче белән үзара аңлашып, ярдәмләшеп эшләвен булдыру.

Кыскасы, балаларны сәламәт рухта тәрбияләү – балалар бакчасының изге бурычы, чөнки балаларның күп вакыты бакчада уза, ул аларның икенче өе булып тора. Шунлыктан бакчада нәниләр өчен барлык уңай шартларны тудырырга тырыштык. Балаларның сәламәтлеген саклау, ныгыту, аларның физик һәм интеллектуаль үсешен тәэмин итү йөзеннән, эшебезне планлаштырудан башладык, планнарны балалар бакчасының эшен камилләштерү буенча үзгәрешләр кертеп һәм яңа бурычлар куеп оештырдык. Яшь үзенчәлекләренә туры китереп һәр төркемдә чыныктыру планы төзелде, аның буенча эш оештырылды; сәламәтлек почмагы, экскурсияләр оештырылды, анда дару үләннәре турында әңгәмәләр үткәрелде, үләннәрне танырга өйрәтелде; хәрәкәтле уеннар ечен кулланма жиһазлар тупланды; спорт төрләрен кулланып бәйрәмнәр, хәрәкәтләнү күнекмәләрен үстеру буенча күңел ачу кичәләре уздырылды. Тәрбиячеләребез көндәлек режимны төгәл үтәп, белем-тәрбия бирү эшен дөрес оештырдылар. Иртәнге гимнастика, физкультура

эшчәнлекләре ел буена программага нигезләнеп, тиешле дәрәҗәдә алып барылды. Физкультура эшчәнлекләрендә иң беренче балаларның активлыгына игътибар ителде, дәрес уздыру төрләре үзгәртелде, яңалыклар кулланылды. ФДББС туры китереп үткәрелгән шөгыльләр бик кызыктыручан дип табылды,

Бакчада физкультура эшчәнлекләре атнага өч тапкыр уздырылды - берсе, һава торышы уңай булганда, ачык һавада узды. Эшчәнлекләрдә түбәндәге мәсьәләләрне тормышка ашырдык:

-балаларның үсешенә һәрвакыт игътибарлы булу;

-балаларга тормышта кирәкле хәрәкәт күнекмәләре бирү;

-сәламәтләндерү, чыныктыру эшенә шартлар булдыру;

-балаларның сәламәтлекләрен ныгыту, көчен, җитезлеген үстерү;

-сәламәтләндерү юнәлешендә төрле физик күнегүләр белән даими шөгыльләнүгә ихтыяҗ булдыру;

-заман таләпләренә туры килгән прграммалар куллану, яңалыкка омтылу.

Балаларны сәламәтләндерү программасы түбәндәге эш төрләрен кертеп төзелде:

1- чыныктыру ысуллары;
2- грипптан, салкын тиюдән саклану чаралары;
3- яссытабанлыкны, күз күреме бозылуны кисәтү;
4- гәүдәне торышына игътибар.

Грипп, ОРЗ чорында медсестра группада сарымсак инголяциясе ясады, тәрбиячеселәр һәм әти-әниләр сарымсактан төймә ясап, балаларга тактылар. Эшебезнең нәтиҗәсе - грипп эпедимиясе вакытында бакча карантинга ябылмады, авыручы балалар саны да аз булды.

Чыныктыру, сәламәтләндерү процедураларын башкарганда тәрбияче түбәндәге гигиена шартларын һәм таләпләрен төгәл үтәде:

-бүлмә һавасының саф булуы;

-бинадагы һава температурасының нормада булуы;

-киемнәрнең һава температурасына карап дөрес сайлануы;

-актив хәрәкәт режимы.

Бу юнәлештәге эшнең нәтиҗәсе ата-аналардан да бәйле. Без аларга сәламәт яшәү рәвешен формулаштыру принципларын өй шартларында да үтәү кирәклеген искәртеп тордык.

Бакчада ел буена көндәлек режим төгәл үтәлә, йоклар алдыннан аяк кулларны юу, йокыдан торгач балаларның күңелен күтәрү, балаларны йокыдан уятучы гимнастика ясау, чыныктыру күнегүләре эшләтелә. Һәр төркемдә буш вакытларда даими рәвештә күз гимнастикасы, аваз әйтү гимнастикалары, үз-үзеңә массаж ясау кулланыла. Дөрес туклану, көндәлек режимны, сәламәтлек программасын төгәл үтәү, физкультура, спорт белән даими шөгыльләнү, организмны чыныктыру балаларыбыз сәламәтлегенә уңай тәэсир итте: алар азрак авырды.

**Нәтиҗә:** узган ел белән чагыштырганда, балаларның бакчага йөрү күрсәткеченең югарырак, 1 баланың елга авырып калдырган көн күрсәткеченең кимүе күзәтелә.

**Тәкъдим:** балаларның бакчага даими йөрүен тәэмин итү өстендә ата-аналар белән эш алып барырга; сәламәт яшәү рәвеше эшен камилләштерергә.

## Балалар бакчасы һәм мәктәп белән элемтә

Балалар бакчасы педагоглары Чирмешән лицее укытучылары белән берлектә балаларны мәктәпкә әзерләү буенча җитди эш алып баралар. Бакчада туган матур традицияләрне балалар мәктәптә дәвам итәләр. 2017-2018нче уку елында бакчада тәрбияләнгән балаларның күбесе әлеге лицейга керделәр. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның төрле яклап үстерелеше, тиешле дәрәҗәдә белем һәм тәрбия алуы, заман таләпләренә туры килеп, акыллы, белемле, көндәшлеккә сәләтле шәхес булып формалашуы өчен безнең балалар бакчасында тиешле шартлар тудырылган. 2017 – 2018нче уку елында тәрбиячеләр еллык планда каралган барлык эшләрне дә югары дәрәҗәдә башкарып чыктылар.

**Нәтиҗә:** балалар бакчасы һәм лицей арасында дәвамчанлык буенча 2017-2018 елга планаштырылган чаралар үтәлде.

Балалар бакчасында тәрбия-белем бирү эше җитәрлек дәрәҗәдә куелган, балаларны өйрәтү, төрле яклап үстерү һәм тәрбияләү эшенә зур игътибар бирелә, уңай шартлар тудырылган.

Киләчәктә түбәндәгеләргә игътибар итәргә кирәк:

- бу юнәлештә эшне камилләштерергә;
- тәҗрибәле тәрбиячеләргә эш тәҗрибәсен уртаклашу уңаеннан төрле күләмнәрдә үткәрелгән конкурсларда һәм семинарларда актив катнашырга;
- балалар бакчасының тәрбия-белем бирү эшенә ата-аналарны да җәлеп итәргә;
- педагогик коллективның барлык эшчәнлеген,эштә булган кимчелекләрне бетерүгә юнәлтергә;
- яңа технологияләр ярдәмендә ярдәмендә системалы эшләүне максат итеп куярга.

## 1.3. Тема,максат һәм бурычлар
## 2018-2019 нче уку елына гомуми мәгълүмат

**<u>Балалар бакчасының методик темасы</u>:** "Социаль мөхиткә яраклашкан,сәламәт ,культуралы,яшь үзенчәлекләренә туры килгән белем-күнекмәләр үзләштергән ,белем алганда УМК нигезләнеп ФДББС таләпләрен кабул итә алырлык шәхес тәрбияләү".

**Максат:** ФДББС таләпләрен тормышка ашыру шартларында яшь үзенчәлекләренә карап билгеле белемнәрне һәм күнекмәләрне үзләштергән, белем бирү учреждениесендә уңышлы тәрбия һәм белем алуга әзер булган социаль адаптацияләшкән, сәламәт, мәдәни шәхес формалаштыру.

**Төп бурычлар:**

1. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга кече яшьтән юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтү, тормыш иминлекләрен саклау;
2. Балаларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту,чыныктыру һәм сәламәтләндерү эшен нәтиҗәле итеп оештыру, хәрәкәт активлыгын үстерү өчен шартлар тудыру;
3. Федераль Дәүләт белем стандартлары таләпләренә таянып, инновацион белем бирү программаларын һәм технологияләрне кулланып, педагогларның һөнәри белем дәрәҗәләрен күтәреп, балаларны мәктәпкә әзерләүнең сыйфатын үстерергә.
4. Балаларның иҗади сәләтләрен ачу һәм үстерү.

## 1.4.Балалар бакчасында кулланыла торган программалар һәм укыту-методик кулланмалар(УМК):

1.Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авылының 3 нче "Чишмәкәй" мәктәпкәчә белем муниципаль бюджет учреждениесенең төп белем бирү программасы

2.Р.К. Шәехованың Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы "СӨЕНЕЧ"- 2016ел.

3.Ф.В.Хәзрәтова, З.Г.Шәрәфетдинова, З.Г.Хабибуллина "Туган телдә сөйләшәбез" -2012ел.

4. С.М.Гаффарова, Ч.Р.Гаффарова, Г.З.Гарафиева "Изучаем русский язык" методическое пособие для воспитателей детских садов 4-5 лет, 5-6 лет, 6-7 лет-2013ел.

5. Зарипова З.М., Кидрячева Р.Г., Исаева Р. С. УМК "Говорим по- татарски" (Татарча сөйләшәбез)-2012ел.

6.Р.К.Шаехова Мәктәпкәчә балалар әлифбасы: "Авазларны уйнатып" , Казан,2011.

7.К.В.Закирова "Балачак аланы", балалар бакчалары тәрбиячеләре өчен хрестоматия, Казан, 2011.

8.К.В.Закирова "На поляне детства", хрестоматия для воспитателей детских садов, Казан, 2011.

9.К.В.Закирова, Л.Р.Мортазина "Әй уйныйбыз, уйныйбыз", балалар бакчалары тәрбиячеләре һәм физкультура инструкторлары өчен методик кулланма, Казан, 2013;

10.З.М.Зарипова "Үстерешле уеннар", Казан, 2013

## II - бүлек. “Мәгариф турында” законнарның үтәлеше.
## 2.1.“Мәгариф турында” законнарның үтәлеше буенча эш планы

| № | Чаралар | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1. | Барлык төркемнәрдә дә тәрбия һәм белем бирү эшен туган телдә (татар телендә) оештыру. | Ел дәвамында | мөдир, тәрбиячеләр, педагоглар, рус теленә өйрәтүче тәрбияче |
| | Дәүләт телләре турындагы законны үтәү максатыннан, балаларга татар һәм рус телләрен өйрәтүне оештыру. | Ел дәвамында | мөдир, рус теленә өйрәтүче тәрбияче |
| 2. | Балалар бакчасының 2018-2019 нче уку елының укыту-тәрбия эше планын, рус теле, туган тел һәм башка барлык бердәм аралашу эшчәнлекләре буенча эш программаларын төзү. | август | мөдир, тәрбиячеләр, педагоглар, рус теленә өйрәтүче тәрбияче |
| 3 | Сәламәтләндерү эше планы төзү. | август | Шәфкать туташы. |
| 4 | Балалар бакчасының көндәлек режимын, төркемнәргә бүлеп белем бирү эшчәнлекләренең челтәрен төзү, раслау. | сентябрь | Мөдир |
| 5 | Анкеталар уздыру | сентябрь | Рус теленә өйрәтүче тәрбияче |
| 6 | Төркемнәрдә ата-аналар җыелышларында катнашу | сентябрь | Рус теленә өйрәтүче тәрбияче |
| 7 | Эвакуация планын барлык эшчеләргә җиткерү, бүлмәләр буенча җаваплы кешеләр билгеләү. | сентябрь | Мөдир |
| 8 | Льготаларга ия булган гаиләләрнең исемлеген булдыру. | сентябрь | Мөдир, тәрбиячеләр. |
| 9 | Ике дәүләт телен камил итеп үзләштерү максатыннан, Ф.В.Хәзрәтова, З.Г.Шәрәфетдинова, З.М.Зарипованың “Туган телдә сөйләшәбез”, 2-3 яшь, 3-4 яшь, 4-5 яшь,5-6 яшь, 6-7 яшь З.М.Зарипова, Л.Н. Вәҗиеваның “Туган телдә сөйләшәбез” , 5-6 яшь ,6-7 яшь, С.М.Гаффарова, Ч.Р.Гаффарованың “Изучаем русский язык” Р.К.Шәехованың “Авазларны уйнатып” укыту-методик комплектларын кулланып балаларга татар һәм рус телләрен өйрәтүне оештыру. | Ел дәвамында | Мөдир, Тәрбиячеләр, рус теленә өйрәтүче тәрбияче |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 10 | Татар һәм рус телләрендә мультфильмнар карау, режим моментларда аудио язмалар тыңлау | Ел дәвамында | Тәрбиячеләр, рус теленә өйрәтүче тәрбияче |
| 11 | Күрсәтмә, таратма материалларны яңарту | Ел дәвамында | Тәрбиячеләр, рус теленә өйрәтүче тәрбияче |
| 12 | УМК белән бирелгән дидактик әсбапларны, кассеталарны барлык төркемнәрдә дә булдыру, әти-әниләрнең алар белән ирекле куллана алуын оештыру. | Ел дәвамында | Тәрбиячеләр, рус теленә өйрәтүче тәрбияче |
| 13 | Тематик шөгыльләр үткәрү – “Татар телем-анам теле”, “Гаилә гореф-гадәтләре”, “Әбиемнең сандыгы” | кварталга бер | Тәрбиячеләр |
| 14 | Татар халык бәйрәмнәрен, күңел ачу иртәләре, атналыклар үткәрү-“Сабантуй”, “Нәүрүз”, “Әниемә бүләгем”, “Әтием – минем горурлыгым”. | Ел дәвамында | белгечләр, төркем тәрбиячеләре |
| 15 | Габдулла Тукайның туган көненә багышлап шигырь бәйрәме үткәрү, конкурсларда катнашу | Апрель | Музыка җитәкчесе, тәрбиячеләр |
| 16 | Үзәк китапханә белән балаларның татар телендә китап укуын күтәрү буенча уртак эш алып бару. | Ел дәвамында | тәрбиячеләр |
| 17 | Яңа дидактик уеннар ясау, булганнарын яңарту | Ел дәвамында | Тәрбиячеләр, рус теленә өйрәтүче тәрбияче |
| 18 | “Ачык ишекләр” көнен үткәрү, әти-әниләрне чакыру. | квартал саен | Тәрбиячеләр |
| 19 | Әти-әниләр почмагындагы мәгълүмат-ларны алыштырып һәм тулыландырып тору | ел буе | Тәрбиячеләр |
| 20 | Дәүләт телләренә өйрәтү буенча дидак-тик уеннар конкурсын оештыру, үткәрү | март | Тәрбиячеләр, рус теленә өйрәтүче тәрбияче |
| 21 | Республика, район күләмендә оештырылган конкурсларда актив катнашу | Ел дәвамында | Тәрбиячеләр, рус теленә өйрәтүче тәрбияче |
| 22 | Балаларның туклануын югары дәрәҗәдә оештыру. | даими | Мөдир,хуҗалык мөдире. |
| 23 | Инвентаризация үткәрү. | октябрь | Мөдир, хуҗалык мөдире. |
| 24 | Балаларның иминлеген һәм хезмәтне саклау инструкциясе үткәрү. | кварталга бер тапкыр | Мөдир |
| 25 | Яңа уку елына бакчага килүче балаларның төгәл исемлеген булдыру. | май | Мөдир, тәрбиячеләр |

## III - бүлек. Кадрлар белән эшне оештыру

### 3.1.Кадрлар турында белешмә

| № п/п | Тәрбияченең исем, фамилиясе, отчествосы | Вазыйфасы | Туган елы | Белеме | Педагогик эш стажы | Квалификацион категориясе |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Ахметвалиева Алсиня Ильясовна | Бакча мөдире | 08.12. 1959 | Югары | 39 | |
| 2 | Федотова Рамзия Фаритовна | Музыка җитәкчесе | 11.07. 1970 | Югары | 27 | Югары |
| 3 | Сибгатуллина Анися рустамовна | Уртанчылар төркеме тәрбиячесе | 12.02. 1969 | Югары | 30 | Югары |
| 4 | Гилязова Гульшат Минхановна | Мәктәпкә әзерлек төркеме тәрбиячесе | 17.07. 1966 | Махсус урта | 30 | 1-категорияле |
| 5 | Самарханова Венера Гайсеевна | Кечкенәләр төркеме тәрбиячесе | 29.06. 1972 | Югары | 26 | 1-категорияле |
| 6 | Назырова Гулия Шакирзановна | Икенче кече яшьтәгеләр төркеме тәрбиячесе | 25.04. 1975 | Махсус урта | 20 | 1-категорияле |
| 7. | Фартдинова Гульсина Ростямовна | Мәктәпкә әзерлек төркеме тәрбиячесе | 23.03. 1987г | Югары | 8 | 1-категорияле |
| 7 | Муратшина Гелюся Мансуровна | Укытучы-логопед | 13.01. 1994 | Югары | 3 | - |
| 8 | Мусина Зиля Замиловна | Уртанчылар төркеме тәрбиячесе | 03.02. 1985г | Югары | 5 | - |
| 9 | Шарапова Эльмира Мансуровна | Рус теле тәрбияче | 22.07. 1972 | Югары | 2 | 1-категорияле |
| 10 | Абунагимова Рамиля Раифовна | Физ-ра инструкторы | 24.11. 1982 | Югары | 1 | - |

### 3.2.Социаль активлыкны, үз белемеңне күтәрү. Эш квалификациясен үстерү.

| № | Эш төре | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1 | Тәрбиячеләрнең үзбелемен күтәрү өстендә эш планнарын барлау, раслау. | Август | Мөдир |
| 2 | 2018-2019 нчы уку елына гәҗит-журналларга язылуны оештыру. | Яртыелга бер | Профком җитәкчесе |
| 3 | Семинар, методик берләшмә утырышларында катнашу. | График буенча | Мөдир,тәрбиячеләр |
| 4 | Тәрбиячеләрнең ФДББС буенча белемнәрен күтәрү максатыннын, курсларда булуларын тәэмин итү. | График буенча | Мөдир |
| 5 | Тәрбиячеләрнең аттестация үтүләрен тәэмин итү | График буенча | Мөдир |
| 6 | “Ел тәрбиячесе – 2019” республика күләм бәйгесенең муниципаль турында катнашу. | Декабрь | Мөдир,тәрбиячеләр |
| 7 | Балаларга тәрбия –белем бирү буенча яңа методик әдәбият, әсбаплар белән танышып бару. | Даими | Мөдир |
| 8 | Үзбелемеңне күтәрү планнары төзү һәм өзлексез эш алып бару. | Даими | Тәрбиячеләр |
| 9 | ФДББС өйрәнү буенча белем күтәрү курсларында булган педагоглар белән түгәрәк өстәл артында сөйләшүләр уздырып, тәҗрибә уртаклашу. | Даими | Мөдир, курсларда булган педагоглар |
| 10 | Федераль дәүләт белем бирү стандарты (ФГОС), УМК куллану буенча эшне, балалар бакчасы сайтында чагылдыру | Даими | Мөдир, сайт өчен җаваплы тәрбияче |

### 3.3.Педагогларны аттестацияләү,белем күтәрү курслары

| № | Ф.И.О. | Үткән курс елы | Үтәчәк курс | Үткән аттестация елы | Үтәчәк аттестация елы |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Федотова Рамзия Фаритовна | 2018 | 2021 | 2015 | 2020 |
| 2 | Сибгатуллина Анися рустамовна | 2016 | 2019 | 2014 | 2019 |
| 3 | Гилязова Гульшат Минхановна | 2015 | 2018 | 2014 | 2019 |
| 4 | Самарханова Венера Гайсеевна | 2015 | 2019 | 2016 | 2021 |
| 5 | Назырова Гулия Шакирзановна | 2015 | 2018 | 2015 | 2020 |
| 6 | Фартдинова Гульсина Ростямовна | 2017 | 2020 | 2017 | 2022 |
| 7 | Муратшина Гелюся | 2018 | 2021 | 2018 | 2023 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Мансуровна | | | | |
| 8 | Мусина Зиля Замиловна | 2014 | 2019 | - | 2019 |
| 9 | Шарапова Эльмира Мансуровна | 2017 | 2020 | 2017 | 2022 |
| 10 | Абунагимова Рамиля Раифовна | - | 2019 | - | 2019 |

## 3.4.Аттестациягә баручы педагог белән эш планы

| № | Үткәреләчәк чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплы кешеләр |
|---|---|---|---|
| 1 | Педагогның гаризаларын һәм аттестацион материалларын карап үтү | Сентябрь-октябрь | Мөдир |
| 2 | Педагогның иҗади лабораторияләрен, эш документацияләрен тикшерү, әзерләү | Октябрь | Мөдир |
| 3 | Экспертка экспертиза нәтиҗәсен җибәрү | Ноябрь | Мөдир |
| 4 | Аттестация материалларын туплап бетерү | Декабрь | Мөдир |

## 3.5.Педагогларны аттестацияләү

| №п/п | Педагогның исем, фамилиясе, отчествосы | Вазыйфасы | Нинди категориягә уза |
|---|---|---|---|
| 1 | Муратшина Гелюся Мансуровна | Укытучы-логопед | I-квалификацион категориягә уза |

## 3.6.Тәрбиячеләрнең үз белемен күтәрү темалары

| № | Ф.И.О | Алынган тема | *Форма, отчёт* |
|---|---|---|---|
| 1. | Федотова Рамзия Фаритовна | Профессиональная компетентность педагогов ДОУ в условиях ФГОС | Эш тәҗрибәсеннән чыгып материал туплау |
| 2. | Сибгатуллина Анися рустамовна | Балаларның сенсор сәләтләрен үстерү ( Сенсорное развитие ребенка) | Эш тәҗрибәсеннән чыгып материал туплау |
| 3. | Гилязова Гульшат Минхановна | Влияние занимательного математического материала на развитие познавательной активности у дошкольников | Эш тәҗрибәсеннән чыгып материал туплау |
| 4. | Самарханова Венера Гайсеевна | Развитие мелкой моторики дошкольников | Эш тәҗрибәсеннән чыгып материал туплау |
| 5. | Назырова Гулия Шакирзановна | Дидактическая игра –как форма развитие детей младшего дошкольного возраста | Эш тәҗрибәсеннән чыгып материал туплау |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 6. | Фартдинова Гульсина Ростямовна | Экспериментирование –как средство развития познавательной активности дошкольников | Эш тәҗрибәсеннән чыгып материал туплау |
| 7. | Муратшина Гелюся Мансуровна | Развите артикуляционной моторики у детей с нарушением речи, как эффективное средство коррекции эвукопоизношения | Эш тәҗрибәсеннән чыгып материал туплау |
